**ТАТАСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Югары Колчурино авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Верхнеколчуринского сельского**
**поселения Алькеевского**
**муниципального района**

Адресы: 422873, РТ, Әлки районы, Югары
Колчурино авылы, 8 Март ур., 21
Телефон (84346) 78014

Адрес: 422873, РТ, Алькеевский район,
с. Верхнее Колчурино, ул. 8 Марта д. 21
Телефон (84346)78014

ПОСТАНОВЛЕНИЕ с.Верхнее Колчурино КАРАР

от 02 ноября 2021 № 24

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.08.2021 дәге «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»18№ карарына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.08.2021дәге «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»18№ карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 һәм 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслы системасын эксплуатацияләүгә бәйле булган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2013 елның 28 декабрендәге «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 декабрендәге «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 1221 номерлы карарына төгәл итеп кулланыла.»;

1.2. 1.5 пунктның 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктның 4-7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә килешү нигезендә Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктның 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «Башкарма комитет яки килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе белән» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми pravo.tatarstan.ru порталында халыкка җиткерергә, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Югары Колчурино авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Е.В.Краснова